**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КОМСОМОЛЕЦ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**«28» февраль 2025 ел** **№ 55/1**

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 14 февралендәге 54/1 номерлы карарындагы хатаны төзәтү турында**

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2025 елның 14 февралендәге 54/1 номерлы карары текстында хата китү белән бәйле рәвештә, муниципаль берәмлек Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» Комсомолец авыл җирлеге Советының 2025 елның 14 февралендәге 54/1 номерлы карары преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25, 26 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Комсомолец авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советы»;

2. 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын кертеп, график сурәте белән бергә, 5 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Комсомолец пос. торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Карар басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе О.В. Сурова